**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Иске Казиле авыл җирлеге Бишалаб авылында**
**гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

14 нче декбрь 2019 ел № 3

“Россия Федерациясендә җирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 121-ФЗ номерлы Федераль законнын 25,1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле узидарә турында” 2004 елнын 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 нчы елның 14 нче декабрендә булып узган гражданнар жыены нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде: «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлегенә кергән Бишалаб торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән (көндезге формада белем алучы студентлардан тыш) 2020 елда 1800 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны, җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча түбәндә язылган эшләрне хәл итүгә куллану белән килешәсезме:

Бишалаб авылында юлларны ремонтлау һәм карап тоту;
- торак пункт территорияләрен төзекләндерү, шул исәптән чүп үләннәрен чабу;
- күмү урыннарын тәртиптә тоту һәм ремонтлау, зиратка капка кую;
- беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 17 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 10 кеше тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 10 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте**:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге составына керүче Бишалаб авылы халык җыенын узган дип таныргa, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип санарга.

2. «2020 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлеге территориясе, Бишалаб авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән (көндезге формада белем алучы студентлардан тыш) 1800 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган

акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме:

- торак пункт территорияләрен төзекләндерү, шул исәптән чүп үләннәрен чабу;
- күмү урыннарын тәртиптә тоту һәм ремонтлау, зиратка капка кую;
- беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү» соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. 2020 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлеге территориясе, Бишалаб авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән (көндезге формада белем алучы студентлардан тыш) 1800 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерергә:

- торак пункт территорияләрен төзекләндерү, шул исәптән чүп үләннәрен чабу;
- күмү урыннарын тәртиптә тоту һәм ремонтлау, зиратка капка кую;
- беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү».

4. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

1) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Иске Казиле авылы, Һади Такташ ур., 4;
2) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Каратал авылы, Күпер урамы, 5;
3) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Атабай авылы, Үзәк урамы, 14; шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче ,
Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Иске Казиле авыл җирлеге
башлыгы: И.Х.Сәгдиев